СОВЕТ ЕРЫКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**22.03.2019** Зирекле авылы **№ 89**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 45_1 статьясы таләпләренә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл авыл җирлеге Уставына, гамәлдәге законнарга туры китерү максатында

**Зирекле авыл җирлеге Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен расларга (Кушымта № 1).
2. Үз көчен югалткан дип танырга:

2017 елныц 5 июнендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 44 номерлы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Советы карары;

Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2018 елның 09 июнендә 66 номерлы «Зирекле авыл җирлеге Советының 2017 елның 5 июнендәге 44 номерлы «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары.

1. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми порталында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Зирекле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **В.А.Данилова**

Алексеевск муниципаль районының
Зирекле авыл җирлеге
Советы карарына кушымта
22.03. 2019 № 89

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авылы җирлеген төзекләндерү, анда чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, әйләнә-тирә мохитне саклау турында Федераль закон, халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген саклау, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм муниципалитетның башка норматив хокукый актлары нигезендә эшләнгән.
2. Әлеге кагыйдәләр, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, барлык физик һәм юридик затлар тарафыннан үтәлергә тиеш.
3. Проектлау һәм территорияләрне төзекләндерү элементларын урнаштыру шәһәр төзелеше һәм җир законнары нигезендә, махсус нормалар һәм кагыйдәләр, дәүләт стандартлары, авыл җирлегенең Генераль планы, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, билгеләнгән тәртип буенча расланган проект документлары нигезендә гамәлгә ашырыла.
4. Әлеге кагыйдәләр авыл җирлеге территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын җыю, чыгару, ташу, утильләштерү һәм эшкәртү буенча мөнәсәбәтләрне җайга салмый.

## II. Төп төшенчәләр

1. Әлеге кагыйдәләрне гамәлгә ашыру максатларында түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

җирле әһәмияттәге автомобиль юлы – транспорт чаралары хәрәкәте өчен билгеләнгән һәм автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса чикләрендәге җир кишәрлекләрен, аларда яки алар астында урнашкан конструктив элементларны (юл полотносы, юл өслеге һәм шуңа охшаш элементлар), технологик өлеше булган юл корылмаларын – саклагыч юл корылмалары, ясалма юл корылмалары, автомобиль юлларын төзекләндерү элементларын – үз эченә алган транспорт инфраструктурасы объекты;

территорияне төзекләндерү – авыл җирлеге территориясенең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, авыл җирлеге территориясен һәм аның территориясендә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми

файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, корылмаларны, тирә-юньне карап тотуга юнәлтелгән, әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге;

витрина – фасадның бер өлешен биләп, тоташ пыяла белән тышланган уем (тәрәзә, витраж);

газон – парклар өчен фон, ландшафт композициясенең мөстәкыйль элементы буларак махсус орлыклар чәчеп үстерелгән яисә табигый юл белән үскән үлән;

йорт – ишегалды корылмалары булган шәхси торак йорт һәм әлеге йорт урнашкан җир кишәрлеге;

ишегалды корылмалары – җир кишәрлегендә урнашкан вакытлыча ярдәмче корылмалар (базлар, лапаслар һәм башкалар);

бина – бердәм күләмле төзелеш системасыннан гыйбарәт (төзелешкә бер тапкыр бирелгән рөхсәт нигезендә төзелгән), автоном рәвештә торырга, төзекләндерелергә һәм эксплуатацияләргә мөмкин булган капиталь төзелеш объекты;

яшел үсентеләр – табигый һәм ясалма рәвештә барлыкка килгән агач-куак, үләннәр җыелмасы (шул исәптән парклар, урманнар, аеруча саклаулы табигать территорияләре, скверлар, бакчалар, газоннар, чәчәк түтәлләре, шулай ук аерым торучы агачлар һәм куаклар);

җир кишәрлеге – аерым бер әйберләргә карата урынын билгеләргә мөмкинлек бирүче сыйфатлары булган җир өслегенең бер өлеше;

җир эшләре – авыл җирлегендә грунт катламын бозу яки камилләштерү юлы белән җир катламын алу, грунт җәю яки камилләштерелгән юллар һәм тротуарлар җәю (салу) белән бәйле эшләр;

инженерлык коммуникацияләре – авыл җирлеге территориясендә булган яки төзелүче суүткәргеч, канализация, җылылык, торба үткәргечләр, электр тапшыру линияләре, элемтә һәм башка инженерлык корылмаларыннан торган тәэмин итү челтәрләре;

җемелдәвекле яктылык - яктылык агымының характеристикасын (төс, ачыклык, чиратлашу һәм башкалар) алмаштыруны күздә тота торган динамик нәтиҗә;

тышкы яктырту – тәүлекнең караңгы вакытында урамнарны, мәйданнарны, паркларны, скверларны, ишегалларын һәм авыл җирлегендәге җәяүлеләр юлын яктырту очен билгеләнгән элементлар җыелмасы;

рөхсәтсез чүплек – юридик яки физик затлар эшчәнлеге барышында 50 кв. метрдан артык мәйданда 30 куб. метрдан артык күләмдә барлыкка килгән каты көнкүреш һәм зур габаритлы төзелеш калдыкларын, башка чүп-чарны рөхсәтсез туплау (җыю) урыннары;

стационар булмаган сәүдә объекты – җир кишәрлеге белән бәйләнмәгән, инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтырулар (технологик тоташтыру) булу яки булмауга карамастан вакытлыча торгызылган корылма яки конструкция рәвешендәге сәүдә объекты, шул исәптән күчмә корылмалар;

яшелләндерү – үсемлек компонентларын актив кулланып, иженер

эшләренең төрле төрләре (вертикаль планлаштыру, агач ябалдашларын кисү һ.б.) белән бәйле комплекслы процесс, һәм яшелләндерелгән территорияләрне төзекләндерү: агачлар, шул исәптән куаклар утырту, үләнле газоннар, чәчәк түтәлләре, махсуслаштырылган бакчалар булдырып җирлек тирәлеген формалаштыруны тәэмин итүче, территорияне төзекләндерү һәм ландшафт ясау элементы;

яшелләндерелгән территория – табигый барлыкка килгән үсемлекләр, ясалма төзелгән бакча-парк комплекслары, бульварлар, скверлар, газоннар, чәчәк түтәлләре булган, торак иҗтимагый, эшлекле, коммуналь, җитештерү билгеләнешендәге объектлар аз булган, чикләрендәге өслекнең 70 проценттан да ким булмаган өлеше үсемлек белән капланган территория;

җәмәгать транспортын көтү тукталышы – җәмәгать транспортына туктау, пассажирларны утырту һәм төшерү зонасы, шулай ук пассажирларга җәмәгать транспортын көтү зонасы булган махсус җиһазландырылган мәйданчык;

җәяүлеләр зонасы – халыкка җәяү йөрү, мәдәни-көнкүреш максатларда хәрәкәт итү өчен файдаланыла торган, шулай ук транзит хәрәкәт итү максатларында билгеле бер характеристикаларга ия: зур тизлекле җир өсте һәм җәмәгать транспорты өчен тукталышлары булган, хезмәт күрсәтү объектлары күп булган, тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр, рекреацияләр булган, җәяүлеләр агымының суммар тыгызлыгы югары булган җирлек территориясе участоклары. Җәяүле зоналар эспланадаларда (ачык урыннарда), җәяүлеләр урамында, торак пункт мәйданының җәяүлеләр йөрү өчен билгеләнгән өлешләрендә формалашырга мөмкин;

йорт яны территориясе – яшелләндерү, төзекләндерү элементлары булган күп фатирлы йорт һәм әлеге йортка хезмәт күрсәтү, эксплуатацияләү, төзекләндерү өчен билгеләнгән, билгеле бер җир кишәрлегендә урнашкан объектлар салынган җир участогы;

якын-тирә территория – бина, корылма, җир кишәрлеге янындагыгомуми файдаланууда булган территория, әгәр мондый җир кишәрлеге булса, аның чикләре бинадан, корылмадан ераклык билгеләү юлы белән билгеләнә,әгәр мондый җир кишәрлеге рөхсәт ителгән файдалану төренә, функциональ билгеләнешенә, мәйданына һәм башка факторларга бәйле рәвештә барлыкка килсә, җир кишәрлеге чикләреннән чыгып исәпләнә:

күп фатирлы йорт территориясе каршындагы җир кишәрлегетөп фасад ягыннан 5 метр радиуста яисә урамның машиалар йөри торган өлешенә кадәр(объект юл буенда урнашкан очракта);

шулай ук төп фасад ягыннан биналар территориясе каршындагы җир кишәрлеге10 метр радиуста яисә урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр(объект юл буенда урнашкан очракта) башка яклардан - 10 м радиуста;

төзелеш мәйданчыкларының якын-тирә территорияләрегамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә 20 м радиуста һәм аларга керү юлында 20 м радиуста;

йорт каршындагы территория5 метр ераклыкта яки урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр(объект юл буенда урнашкан очракта);

стационар булмаган объектларның якын-тирә территориясеурамның тышкы чигеннән 10 м ераклыкта һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);

базарларның, сәүдә һәм җәмәгать тукланучы оешмаларының (рестораннар, кафе, кибетләр) якын-тирә территориясе кишәрлек чикләреннән 50 м радиуста һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);

автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса чикләрендә урнашкан ягулык салу станцияләренең якын-тирә территориясе чикләреннән50 м радиуста;

гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләренең якын-тирә территориясеучасток чикләреннән 10 м радиуста һәм урамның машиналар йөри торган олешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта;

махсуслаштырылган оешмалар – төзелгән муниципаль контрактлар нигезендә җирлек территориясен төзекләндерү өлкәсендәге эшчәнлекнең махсус төрләрен гамәлгә ашыручы, төрле оештыру-хокукый формадагы юридик затлар;

территорияләрне карап тоту – җир кишәрлегендә урнашкан биналарның фасадларын, корылмаларны, кече архитектура формаларын, рәшәткәләрне, төзелеш мәйданчыкларын, яшел үсентеләрне, җир астындагы инженер коммуникацияләрен һәм аларның конструктив элементларын, транспорт инфраструктурасы объектларын үз вакытында ремонтлау һәм карап тоту белән бәйле чаралар комплексы;

җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту – юлның, юл корылмаларының, юлларны комплекслы төзекләндерү элементларының транспорт-эксплуатация торышын тәэмин итүче эшләр комплексы;

тышкы мәгълүматны урнаштыру чарасы – оешмалар урнашкан урыннарда һәм (яки) турыдан-туры товар сату, хезмәт күрсәтү урыннарындагы биналарда, йортларда, шул исәптән капиталь булмаганнарында, мәгълүмати бизәлеш булдыру максатында, кулланучыларга мәгълүмат җиткерү очен «Кулланучылар хокукын яклау турында» Федераль закон нигезендә мәҗбүри булган оешманың фирма исеме (атамасы), аның урнашкан урыны (адресы) һәм аның эш вакытлары турында мәгълүмат, шулай ук закон нигезендә яки эшлекле әйләнеш гадәтеннән чыгып урнашырга тиешле һәм реклама белән бәйле максатларны күздә тотмаган мәгълүматлар тупланган конструкция рәвешендәге территорияне төзекләндерү элементы. «Тышкы мәгълүматны урнаштыру чаралары» һәм «Тышкы мәгълүмат чарасы» төшенчәләре бердәй;

территорияләрне җыештыру – җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, махсус билгеләнгән урыннарга чыгару, башка төрле чүп-чар, кар чыгару, шулай ук халыкның экологик һәм санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә, әйләнә-тирә мохитны саклауга юнәлтелгән башка чаралар белән бәйле эшчәнлек торе;

күрсәтүче билгеләр:

- биналарның фасадларында урнаштырылган урам исемнәре, йорт

номерлары, подъезд һәм фатир номерлары, янгын гидранты урнашкан урыннарны, грунтның геодезик билгеләрен, инвалидлар өчен объектның уңайлы үтү юлларын күрсәтүче билгеләр;

- аерым стелла рәвешендә торучы җирлек, анда туризм өлкәсендәге объектларның, мәгариф объектларының, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең урнашкан урыннары турында гомумиләштерелгән мәгълүматны үз эченә алган күрсәтүче билгеләр;

- вәкаләтле органнар – үз компетенциясе чикләрендә авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру, координацияләү һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы җирлек (район) башкарма комитеты органнары;

- фасад – бинаның тышкы ягы (алгы ягы, яны, ишегалды ягы);

- фронтон – бинаның соңгы кат тәрәзәләрендәге иң югары ноктадан яки чыгып торган җиреннән фасадның югары билгесенә кадәр үлчәнелүче бина фасадының түбәгә кадәрге төгәлләүче өлеше (кыегы);

- төзекләндерү элементлары – территорияне төзекләндерүнең состав өлешләре буларак кулланыла торган декоратив, техник, планлаштыручы һәм конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәү эшләренең, шул исәптән биналарның, корылмаларның төрле төрләре, кече архитектура формалары, стационар булмаган төзелеш объектлары, корылмалар мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган күрсәтүче билгеләр.

## III. Территорияләрне төзекләндерүгә, карап тотуга һәм җыештыруга гомуми таләпләр

1. Җирлекнең бөтен территориясе, анда урнашкан барлык биналар (шул исәптән торак йортлар) һәм корылмалар (алга таба - биналар, корылмалар) төзекләндерелергә, карап торылырга һәм җыештырылырга тиеш.

2. Гомуми файдаланудагы территорияләрне, шул исәптән җирле әһәмияттәге мәйданчыклар, урамнар, автомобиль юллары, парклар, пляжлар, башка объектлар урнашкан җир кишәрлекләрен, карап тоту һәм җыештыру эшләрен вәкаләтле органнар үз вәкаләтләре чикләрендә гамәлгә ашыра.

Оештыру-хокукый формасы нинди булуга карамастан, физик һәм юридик затлар(алга таба - җир кишәрлекләре хокукына ия булучылар), милек хокукында һәм башка төрле әйбер яисә мәҗбүри хокукта үз карамагында булган җир кишәрлеге территориясен, шулай ук гамәлдәге законнарда һәм әлеге Кагыйдәләрдә каралган күләмдә, мөстәкыйль рәвештә яки махсус оешмаларны үз акчалары хисабына җәлеп итү юлы белән биналарны, корылмаларны карап тотуны һәм җыюны гамәлгә ашыралар.

Шәхси торак йортларның территорияләрен карап тоту һәм җыештыру мондый йортларның милекчеләре (яллап торучылары) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Әгәр бина, корылма милек яки башка әйбер хокукында,мәҗбүри хокукта берничә затныкыбулса, фасадны карап тору милек хокукындагы өлешкә яки

күчемсез милек объектына булган башка хокукка пропорциональ рәвештә билгеләнә.

Җир кишәрлеге территориясендә төрле затларыкы булган берничә бина, корылмалар урнашкан очракта,территорияне карап тоту һәм җыештыру чикләре биналарның, корылмаларның барлык милекчеләре яки башка хуҗалары (кулланучылар) арасында тигез өлешләрдә яисә якларның килешүе нигезендә билгеләнә ала.

Физик яки юридик зат карамагында булган җир кишәрлеге билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта,территория аның карамагында булган җир кишәрлегенең фактик чиге буенча җыештырылырга тиеш

Күпфатирлы йортларның йорт яны территорияләрен карап тоту һәм җыештыру күпфатирлы йортлар белән идарә итүнең бер ысулы нигезендә гамәлгә ашырыла:күпфатирлы йорт белән турыдан-туры әлеге йорттагы биналарның милекчеләре (алга таба-идарәче оешмалар)идарә иткәндә торак милекчеләре ширкәте яки торак кооперативы яки башка махсус специальләшкән кулланучылар кооперативы,идарәче оешма, күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкаручы затлар тарафыннан.

3. Муниципаль милектә булган якын-тирә территорияне карап тоту һәм җыештыру махсус оешмаларны җәлеп итү юлы белән җирле бюджет чаралары хисабына башкарыла.

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм җыештыру муниципаль сатып алу нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен үткәрүгә конкурста җиңгән махсуслаштырылган оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Урамнардагы, юллардагы, юл буйларындагы грунт һәм өслек сулары агу җайланмаларын, корылмаларны карап тору һәм җыештыру аларны эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан башкарыла.

5. Вәкаләтле органнар авыл җирлеге территориясен, шул исәптән гомуми файдаланудагы терриорияләрне, билгеләнгән вәкаләтләре чигендә, карап тоту һәм җыештыру эшләрен башкаруны тикшереп торалар.

## IV. Биналарны, корылмаларны карап тоту буенча гомуми таләпләр.

1. Биналарны, корылмаларны һәм алар урнашкан җир кишәрлекләрен карап тору шул биналарны, корылмаларны һәм алар урнашкан җир кишәрлекләрен төзекләндерүне үз эченә ала.

2. Бина, корылмаларның фасадларының тышкы кыяфәтен ясаганда төп шарт булып архитектура-сәнгать образының, материалларның һәм төсләрнең стиль бердәмлеге тора.

Фасадның арым участоклары, детальләр, элементлар һәм өстәмә җиһазлар комплекслы карар нигезендә урнаштырылрга тиеш. Тышкы мәгълүматны урнаштыру чаралары, учреждение такталары, эш вакытын күрсәткән табличкларыннан тыш, паспорт нигезендә урнаштырылырга һәм кулланылырга тиеш.

3. Төсләр куллану фасадның характеристикаларына һәм стиленә туры килергә, объектның функциональ билгеләнешенә, әйләнә-тирә мохиткә туры килергә тиеш, шулай ук бина фасадларының төсләре паспорт нигезендә билгеләнә. Бинаны, корылманы эксплуатацияләгәндә яки ремонтлаганда төс тонын үзгәртү рөхсәт ителми.

4. Биналарның, корылмаларның фасадларында төзелешкә, декоратив бизәкләү һәм инженерлык элементларына кагылышлы зыян булмаска һәм алар тиешле эстетик хәлдә сакланырга тиеш. Бина фасадының буявына килгән зыян фасад мәйданының 1% нан артмаска тиеш.

5. Мәдәни мирас объектларын саклау зоналарында урнашкан биналарның фасадларын бизәү мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә закон һәм мәдәни мирас объектларын саклау зоналары проекты нигезендә вәкаләтле органнар белән килештереп, биналарның архитектурасы стилендә, шул исәптән урамнардагы төзелешләрнең гомуми стильлендә башкарыла.

6. Ремонттан соң фасадларны кабул итү, яңадан җиһазландыру һәм буяу кабул итү комиссиясе тарафыннан башкарыла.

7. Биналарның, корылмаларның фасадларын карап тотуга түбәндәгеләр керә:

- үз вакытында үткәрелүче ремонт (3 елга бер тапкырдан да ким түгел), агымдагы ремонт (фасадның фактик торышын исәпкә алып, 5-6 елга 1 тапкыр), конструктив элементларны торгызу һәм фасадларны, шул исәптән керү ишекләрен һәм ишек башларын, балкон коймаларын, кәрнизләрне, баскыч алларын һәм аерым бусагаларны, төшү юлларының киртәләрен, витриналарны, цокольле тәрәзәләрне һәм подвалга керү юлларын, декоратив детальләрне һәм башка конструктив элементларны торгызу һәм аларны буяу, бизәү;
- су үткәргеч җайланмаларның, торбаларның үз урынында һәм төзек хәлдә булуын тәэмин итү;
- ялгаулы урыннарының, ярык һәм тишелгән урыннарның герметик һәм төзәтелгән булуын тәэмин итү;
- фасад өслекләрен, шул исәптән фасад элементларын, аларның торышы һәм эксплуатацияләү шартларыннан чгып, вакытында чистарту һәм юдыру;
- язулардан, белдерүләрдән һәм башка мәгълүмати-басма продукциядән, шулай ук төшерелгән граффитидан чистарту;
- элмә такталарны эксплуатацияләнмү (арендатор китү сәбәпле) яки бинаның фасады үзгәртелү сәбәпле урыннарыннан алу.

8. Фасадларны эксплуатаңияләгәндә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- диварларның өслекләренә, фасадларның чыгып торган җирләренә, эргәләргә зыян китерү (пычрату): су аккан эзләр булу, буяу кубу, ярыклар булу, штукатурка яки тышлык кубу, салынган кирпечкә зыян килү, тимер-бетон конструкңияләрнең саклау катламы кубу һәм башкалар;
- биналарның һәм корылмаларның архетиктур, сәнгати-скульптура

детальләренә: колонналар, барельефлар, балчыктан ясалган бизәкләр, орнаментлар, мозаика, сәнгати буяуга зыян китерү (проект документлары белән каралган очракларда булмаса);

- панельләр кушылган урыннарда герметизация бозылу;
- фасадны һәм аның элементларын бу бина яки корылма очен проект паспортында билгеләнмәгән төсләр һәм материаллар белән бизәү һәм буяу;
- вәкаләтле орган белән килешенмичә, проспект, урам, тыкрык, мәйдан исемнәре, бина, корылма яки корпус номеры күрсәтелгән күрсәткеч билгеләр урнаштыру һәм эксплуатацияләү;
- архитектур детальләрдә, аларның өслегенә зыян китерерлек, урам антенналары һәм кондиционерлар урнаштыру.

9. Тышкы күзәтү видеокамералары элмә такталар, ишек яки тәрәзә башларында, балкон аслрында, фасадның архитектура детальләре, декор һәм кыйммәтле элементлары булмаган өлешләрендә урнаштырыла.

Колонналарда, фронтоннарда, тәрәзә йөзлекләрендә, пилястраларда, порталларда, козырекларда, балкон асларында тышкы күзәтү видеокамераларын урнаштыру рөхсәт ителми.

10. Подъездларга кергән урыннарда мәгълүмати стендлар урнаштыру рөхсәт ителә.

11. Биналарның, корылмаларның фасадлары күрсәтүче билгеләр белән җиһазландырылырга тиеш.

12. Урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәтүче билгеләр, әлеге Кагыйдәләр нигезендә билгеләнгән урыннарда, Татарстан Республикасының 2 дәүләт телендә урнаштырыла:

- җир өслегеннән 2,5 метрдан да ким булмаган һәм 5,0 метрдан да артык булмаган биеклектә;
- фасадның тышкы почмагыннан 1,0 метрдан да артык түгел;
- фасадның архитектур үзенчәлекләрен исәпкә алып;
- фасадның төп һәм ян ягында – фасадның уң ягында;
- бердәм горизонталь һәм вертикаль кучәрне исәпкә алып.

13. Аерым торучы күрсәтүче билгеләр (стеллалар) урнаштыру рөхсәт ителми:

- Нейтраль булмаган төсләрдә (соры, кара, көрән яки башка караңгы төсләрдә) һәм (яки) табигый булмаган (табигый материалларга охшатып ясалган) материалларда ясау;
- биеклеге 6,0 метрдан артык түгел;
- фундаментны бозмыйча;
- аларны урнаштыру тротуарның норматив киңлеген тарайтса (0,75 м дан ким), шулай ук автомобильләр узып йөри торган урыннарда, парковкалар һәм машиналар туктап тора торган урыннарда;
- тирән фундамент булган урыннарда, җир кишәрлеге чикләрендә объект проектында каралган яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) урынына утыртылган, агач кәүсәләреннән 5,0 м,.

14. Янгын гидрантлары, полигонометрик билгеләр, геодезик билгеләр урнашкан урыннарны күрсәтүче билгеләр биналарның, суүткәргеч һәм канализация челтәрләре коеларының цокольлерендә урнаштырыла. Янгын гидрантларын, полигонометрик билгеләр урнашкан урыннарны күрсәтүче һәм геодезик билгеләрне урам исемнәре, йорт номерлары, шулай ук архитектура детальләре, декоратив-сәнгать бизәлеше, пыяла белән тышланган урыннар, капкалар, ишекләр белән янәшә урнаштыру рөхсәт ителми.

15. Күрсәтүче билгеләрне чиста һәм төзек хәлдә тотарга кирәк.

16. Бина, корылмаларның керү юлларын ишек башлары (козыреклар), инвалидлар һәм хәрәкәте чикле булган кешеләр өчен уңайлылык тудыручы җайланмалар (пандуслар, таяну җайланмалары һ.б.), чүп савытлары белән җиһазландырырга кирәк.

Җәяүлеләр йөри торган төп урыннарда, сәламәтлек саклау учреждениеләре һәм башка гомуми кулланылышта булган объектлар урнашкан урыннарда, инвалидлар һәм картлар йортларында баскычларның авышлыгы 50 промиллдән артык булмаска һәм алар пандуслар белән җиһазландырылырга тиеш.

Пандус тайдырмый торган материалдан эшләнгән, кытыршы өслекле, горизонталь уемнарсыз, булырга тиеш. Пандуслар янында койма рәвешендәге киртәләр булмаган очракта биеклеге 75 миллиметрдан ким булмаган бортиклар һәм тотыну җайланмалары кую күздә тотыла. Бордюр пандусының авышлыгы 1: 12 булганда кабул ителә. Төшү һәм менү юлларындагы беренче баскыч кырыйларын ачык контраст төстәге буяуларга буярга кирәк.

Пандусларның башында һәм ахырында булган горизонталь участокларны якындагы өслекләрдән текстурасы һәм төсе белән аерылып торырлык итеп ясарга кирәк.

Баскычларның һәм пандусларның ике ягында да 800-920 мм биеклектәге, стенадан 40 мм ераклыкта урнашкан түгәрәк яки турыпочмаклы тотынгыч җайланмалар кую карала. Баскычлар 2,5 метрдан киңрәк булган очракта уртада аеруп торучы тотынгыч җайланмалар кую күздә тотыла. Тотынгыч җайланмаларның озынлыгы, ике яктан да, 0,3 метрга озынрак итеп урнаштырыла. Тотынгыч җайланмаларның конструкциясе кул белән тимергә тотынмаслык итеп эшләнелергә тиеш.

Киртә булып торырлык пандус конструкцияләр булмаган очракта, биеклеге 75 мм ким булмаган, бортиклар ясау күздә тотыла.

17. Керү юлларын, бина, корылмаларның фасадларын яңарту яки үзгәтеп ясау эшләрен проектлаганда һәм эксплуатацияләгәндә тротуарлар һәм норматив киңлеге минималь булган тортуарлы урам юллары челтәрләре зоналарында якын-тирә территориягә караган тротуарларда җиңел конструкцияле керү юллары элементларын (баскычлар, пандуслар, ишек төпләре, яшелләндерү) ясау тыела.

18. Кыш айларында биналарның хуҗалары һәм башка хокукый затлар, шулай ук күпфатирлы йортлар каршында оештырылган идарәче оешмалар тарафыннан түбәләрне кардан, бозланулардан, боз сөңгеләреннән вакытында чистарту эшләре оештырыла. Кар катламы 30 см, ә температура 0 яки аннан да югарырак булганда 10 см калын булмаска тиеш.

Түбәләрне кардан чистарту эше җәяүлеләр йөри торган якта башкарылса, махсус киртәләр куеп, барлык саклану чараларын күреп, көннең якты вакытында гына алып барылырга тиеш. Түбәдән җәяүлеләр һәм машиналар йөри торган юлларга төшерелгән кар һәм бозлар тиз арада чистартып алынырга тиеш.

19. Түбәләрдән кар һәм боз төшерелгәндә, боз сөңгеләреннән чистарту эшләре вакытында агач һәм куакларны, электр чыбыкларын, яктылык һәм телефон чыбыкларын, юл билгеләрен, юл буендагы светофорларны, киртәләрне, юл күрсәтүче җайланмаларны, декоратив бизәкләү һәм инженер элементларын саклау өчен барлык шартлар да тудырылырга тиеш. Алда күрсәтелгән элементларга зыян китерелгән очракта, алар түбәләрне чистартучылар һәм зыян салучы затлар тарафыннан үз акчаларына, яңадан торгызыла.

20. Бина һәм корылмаларның түбәләре, җәяүлеләр һәм җәяүлеләр йөри торган юлларга түбәдән су акмаслык итеп, су агу юллары белән тәэмин ителгән булырга тиеш. Улаклар, воронкалар һәм су агу торбалары үзара тыгыз тоташтырылган һәм җыелган су агымын үткәрелерлек булырга тиеш. Җәяүлеләр йөри торган юллар ягына чыгучы су агу торбалары җәяүлеләр йөри торган юлның кырыена кадәр чыгарылырга тиеш.

21. Шәхси торак йортларның милек хуҗалары (яки) яллап торучылар (алга таба – торак йорт хуҗалары), закон буенча яки килешенү буенча башкалар булмаган очракта:

- өйнең фасадын, рәшәткәләрен (коймаларын), шулай ук йорт чикләрендә урнашкан башка корылмаларның тиешле хәлдә булуын тәэмин итәләр, үз вакытында ремонт һәм буяу эшләрен башкаралар;
- Татарстан Республикасының телләр турындагы законы нигезендә торак йорт диварында урам атамасы, йорт номеры ике дәүләт телендә күрсәтлгән табличкалар булдыруны һәм аларның төзек хәлдә булуын тәэмин итәләр;
- үз хуҗалыгы рәшәткәләренең биеклеген, тышкы кыяфәтен һәм төсен вәкаләтле органнар белән килешенеп ясыйлар.

## V. Җир кишәрлекләрен, юлларны карап торуга гомуми таләпләр.

1. Җир кишәрлекләрен, юлларны карап торуга түбәндәгеләр керә:

- җир кишәрлеген чүптән, яфраклардан, кар һәм боздан (бозланудан) арындыру һәм санитар-гигиеник чистарту;
- гражданнар, оешмалар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән каты көнкүреш калдыкларын, зур габоритлы һәм башка җитештерү, куллану калдыкларын җыю һәм түгү;
- утыртылган яшел үсентеләрне саклау һәм аларны карап тору;
- машиналар йөри торган юлларны, күперләрне, урамнарны, тротуарларны, тыкрыкларны, җәяүлеләр йөри торган урыннарның өслекләрен бозлавыкка каршы материаллар белән эшкәртү;
- карны, бозны (бозлы кар катламнарын) җыештыру, себерү һәм түгү;
- контейнер өчен мәйданчыкларны, чүп савытларын, эскәмияләрне, кече

архитектура формаларын һәм башкаларны кую, чиста һәм техник яктан төзек хәлдә тоту;

- яңгыр һәм эрегән кар суларын агызуны җайлау;
- һаваны тузаннан арындыру һәм дымландыру өчен территориядә су сиптерү;
- коммуналь хезмәт күрсәтүче, инженер коммуникацияләрен (корылмаларны), юллар, күперләр, җәяүлеләр өчен юл аша чыгу урыннарын төзегәннән, реконструкцияләгәннән, төзекләндергәннән һәм башка төрле казу эшләре алып барганнан соң бозылган төзекләндерү элементларын торгызу;
- җир кишәрлеге чикләрендә урнаштырылган коймаларны карап тору, шул исәптән ишелгән (сүтелгән, сүтеләчәк) биналар, корылмалар янында коймалар кую һәм аларны карап тору, территориягә чит кешеләргә керү, рөхсәтсез көнкүреш калдыкларын җыю урыннары ясау мөмкинлеген булдырмау, шулай ук вакытында пычрактан, кардан һәм информацион-басма продукциядән чистартып тору

-чүп үләннәре, шул исәптән Сосновский борщевигын юк итәргә;.

2. Юлларны карап тору эше муниципаль сату нәтиҗәләре буенча, әлеге эшләрне башкаруга карата үткәрелгән бәйгедә җиңгән оешма тарафыннан башкарыла.

3. Юлларны карап торуга түбәндәгеләр керә:

- Юлларны, тротуарларны, ясалма юл корылмаларын, кварталлар арасындагы юлларны төзекләндерү;
- тротуарларны (җәяүлеләр йөри торган юлчыкларны) һәм машиналар йөри торган юлларны, ясалма юл корылмаларын пычрак, чүп, кар һәм боздан (бозлыклардан) арындыру;
- юл өлекләренә су сибү һәм аларны юуу.
- газоннарны һәм яшел үсентеләрне карап тору;
- урамдагы утларның, тоташтыру челтәре баганаларын төзәтү;
- күзәтү һәм яңгыр сулары агып китә торган коеларны ясау, төзекләндерү һәм чистартып тору;
- коймаларны, рәшәткәләрне, турникетларны, кече архитектура формаларын кую, төзекләндерү һәм ел саен буяу.

Хосусый торак йорт милекчеләре (яки) яллаучылар (алга таба - торак йортлар хуҗалары), әгәр законда яки килешүдә башка затлар каралмаган булса:

- йорт яны территориясеннән чистартылган карны транспорт йөрешен тәэмин итәрлек, юл хәрәкәтендә катнашучыларга күзәтүне сакланырлык, машиналар йөрү өлеше тараймаслык итеп, инженерлык коммуникацияләренә һәм корылмаларына, җәяүлеләргә үтеп керү мөмкинлеге калдырып һәм яшел үсентеләрнең сакланышы тәэмин итеп җыялар;

- бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә үзәкләштерелгән канализация булмаса, санитар нормалар нигезендә үз канализацияләрен, чүпбазын, бәдрәф урнаштыралар, аларны даими рәвештә чистарталар һәм дезинфекциялиләр;

- йорт янында үскән үләннәрне чаптыралар;

- билгеләнгән тәртип нигезендә каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны вакытында җыюны һәм чыгаруны тәэмин итәләр.

5. Шәхси торак төзелеше территориясендә рөхсәт ителми:

- йорт биләмәләрендә һәм алар янәшәсендәге территорияләрдә яфракларны, теләсә нинди калдыкларны һәм чүп-чарны яндыру;

- күмер, тара, утын, зур габаритлы калдыкларны, төзелеш материалларын, җитештерелгән продукцияне, шул исәптән авыл хуҗалыгына караган (печән, салам, тирес), чималны, җиһазларныйорт биләмәсе территориясеннән читтә урнаштыру;

- йорт биләмәләреннән читтә транспорт чараларын юу;

- әлеге территориянең машиналар йөри торган өлешләрендә махсус транспорт һәм җыештыручы техниканың үтеп йөрүен кыенлаштыра торган киртәләр урнаштыру;

- йорт биләмәләреннән читтә сүтелгән (төзек булмаган) транспорт чараларын саклау;

- йөк транспортын һәм тагылмаларны, шулай ук башка махсус техниканы (тракторлар, үзйөрешле машиналар) милекче ихатасыннан яки транспорт чараларын урнаштыру өчен махсус билгеләнгән оешма предприятиеләрнең территориясеннән читтә булган урыннарда калдыру;

- якын-тирә территорияне теләсә нинди калдыклар белән чүпләү.

6. Физик һәм юридик затларга, оештыру-хокукый формалары нинди булуга карамастан,юл хәрәкәтендә катнашучыларга күзәтүне кыенлаштырып, транспорт йөртү өчен киртә тудырып, юл йөрү өлешен таратып, юл хәрәкәте иминлегенә куркыныч тудырып,юлланың машиналар йөрү өлешенә кар көртләре өю, чүп-чар һәм көнкүреш калдыкларын чыгару тыела .

## VI. Техник элемтә чараларын, тышкы яктырту объектларын, кече архитектура формаларын, милли объетларны карап торуга гомуми таләпләр

1. Биналарны инженер-техник яктан тәэмин итүгә каралган элемтә челтәрләре, телевидение, радио, Интернет һәм башка шуңа охшаш челтәрләрнең чыбыкларын җир асты (траншея, каналлар, тонельләр) буйлап кертү.
2. Биналарга тышкы коммуникацияләрне башка юллар (һава буйлап, җир өстеннән) кертү, җир астыннан кертү мөмкинлеге булмаганда, эксплуатацияләүче оешмалар тарафынна тиешле техник шартлар тудырылганда гына рөхсәт ителә.
3. Милек хуҗалары техник элемтә чараларын (чыбыкларны, чыбыкларны беркетү җайланмаларын, бүлеп таратучы һәм муфталы тартмаларны һәм башкаларны), шулай ук шулар ярдәмендә тоташтырылучы техник чараларның тиешле халәттә булуын (өзелүләр һәм /яки саклаучы тышлыгы булмавын, буявы кубуын булдырмау, күгәрекле һәм /яки механик бозыклар булмавын, чыбыкларның салынып төшмәве һәм /яки аларның яктылык һәм ут баганаларына) чорналмаган булуын) карап торалар.
4. Урамнар, юллар, мәйданнар, җәяүлеләр йөри торган тротуарлар, торак

кварталлар, йортлар, предприятие, учреждение, оешма территорияләре тәүлекнең караңгы вакытында яктыртылырга тиеш.

Урамнарда, юлларда, мәйданнарда, микрорайон территорияләрендә, торак йорт подъездлары янында ут, кич белән (эңгер-меңгер вакытында) табигый яктылык дәрәҗәсе 20 лк булганда, кабызыла, ә сүндерү – иртәге вакытларда, яктылык 10лк дан югарырак булганда, башкарыла.

5. Гамәлдән чыккан, составында терекөмеш булган лампалар махсус шул макст өчен билгеләнгән бүлмәләрдә сакланырга һәм аларны утильләштерүче предприятияләргә озатылрга тиеш. Алда күрсәтелгән лампаларны чүплекләргә яки чүп эшкәртүче заводларга озатылырга тиеш түгел.

6. Тышкы яктырту җайланмаларының тимер баганалары, кронштейннары һәм башка элементлары чиста халәттә тотылырга, кәкрәйгән булмаска, күгәрексез булырга һәм милек хуҗалары тарафыннан (хуҗалар, кулланучылар) кирәк булган саен, ләкин өч елга бер тапкырдан да кимрәк булмыйча, буялырга, карап торылырга тиеш.

7. Урамдагы, йортлар янындагы яктырту җайланмаларын карап тору, ремонтлау һәм бердәм тышкы яктырту системасына тоташтыру эшләрен, муниципаль сатып алу нәтиҗәләрен урнаштырган, әлеге эшләрне эшләргә рөхсәт алу максатыннан үткәрелгән, бәйгедә җиңгән вәкаләтле орган яки спеңиальләшкән оешма тарафыннан алып барыла.

Торак йортларның тапшыру бүлгечләренә тоташтырган йорт яны утларын карап тоту һәм ремонтлау идарәче оешмалар тарафыннан башкарыла.

Тышкы яктырту җайланмалары эшендә барлыкка килгән, электр үткәргечләре өзелү яки терәк баганаларга зыян китерү белән бәйле бозылулар, билгеле булгач ук, кичекмәстән төзәтелергә тиеш.

8. Электр чыбыкларын, кабельләрне рөхсәтсез, үз белдегең белән, тышкы яктылык челтәрләренә һәм җайланмаларына тотоштыру рохсәт ителми.

9. Тышкы яктырту объектлары яки тышкы яктырту чаралары белән җиһазландырылган объектларның милекчеләре (хуҗалары), шулай ук тышкы яктырту объектларына (чараларына) хезмәт итүче оешмалар:

- урамнарны, юлларны тиешенчә яктыртуны, баганаларның һәм яктырткычларның, яктырту җайланмаларының сыйфатын күзәтеп торалар, бозылган яки зыян күргән очракта вакытында ремонт ясыйлар;
- яктыртуны, шул исәптән билгеләнгән тәртип нигезендә, архитектур яктырту утларын кабызуны һәм сүндерүне тәэмин итеп торалар;
- тышкы яктырту утларын кую, карап тоту, урнаштыру һәм эксплуатацияләү, шулай ук рәсмиләштерү кагыйдәләрен үтиләр;
- тышкы яктырту фонарьларын үз вакытында алмаштыралар.

Аерым яктырткычларның, яктылык чыганакларының, төзексез булуы билгеле булгач яки төзексезлек турында хәбәр алынганнан соң, торгызу срогы 10 тәүлектән артмаска тиеш.

10. Кече архитектура формаларына декоратив-сәнгать бизәлеше элементлары (скульптуралар, аерым торучы инсталяцияләр), аерым торучы күрсәтүче билгеләр (стеллалар), мобиль һәм вертикаль яшелләндерү өчен кирәкле

җайланмалар, су җайланмалары, муниципаль җиһазлар, җирлек территориясендәге коммуналь-көнкүреш һәм техник җиһазлар керә.

11. Кече архитектура формаларын карап тору участокларының хуҗалары тарафыннан, гомуми файдаланудa булган территориядә урнашкан җир кишәрлекләре чикләрендә - вәкаләтле орган тарафыннан муниципаль сатып алу нәтиҗәләре буенча әлеге эш төрләрен уздыруга конкурс откан оешма белән килешү нигезендә тәэмин ителә.

12. Кече архитектура формалары хуҗалары:

- кече архитектура формаларының чиста һәм төзек хәлдә булуын карап торалар;
- язгы чорда аларны иске буяулардан, күгәрекләрдән арындыралар, юдырталар, яңартып буйыйлар, шулай ук ватылган элементларын яңаларга алмаштыралар;
- кышкы чорда кече архитектура формаларын, шулай ук алар янына килү юлларын кардан, боздан һәм бозлавыклардан чистарталар;
- шома өслекле киртә куеп комлыклар урнаштыралар һәм андагы комны елга бер тапкырдан да сирәк булмыйча алмаштыралар;
- хуҗалык мәйданчыкларында һәм ял мәйданчыкларында урнаштырылган балалар һәм спорт җиһазларының конструктив элементлары ныклыгын, ышанычлылыгын һәм куркынычсызлык таләпләренә туры килүен күзәтеп торалар;
- фонтаннар эшләгән чорда су өслеген чүптән көн саен чистартып торалар;

13. Рөхсәт ителми:

- кече архитектура формаларын төп билгеләнеше буенча кулланмау (балалар өчен ясалган уен мәйданчыкларында өлкәннәргә ял итү, спорт мәйданчыкларында керләр киптерү һәм башкалар.);
- теләсә нинда мәгълүмати-басма продукцияне кече архитектура формаларына элү һәм ябыштыру;
- кече архитектура формаларын һәм аларның конструктив элементларын вату яки аларга зыян китерү;
- фонтаннарда су коену.

14. Стационар булмаган объектларны урнаштыру муниципаль хокукта билгеләнгән тәртипләр буенча, мондый объектларны урнаштыру схемасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җир участогын арендалау килешүе срогы чыкканнан соң, стаңионар булмаган объект арендатор тарафыннан сүтеп алына, ә җир участогы бушатыла һәм беренчел халәткә китерелә.

- үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру барышында якын-тирә территориядәге яшел үсентеләрнең, газоннарның, бордюр ташларының, кече архитектура формаларының (алар булганда) сакланышын бозмаска

15. Ваклап сату челтәре объектының тышкы габаритлар буенча максималь мәйданы - 60 кв. м. булырга тиеш.

16. Стационар булмаган объектларның хуҗалары булган юридик һәм физик затлар:

- аларны төзәтү һәм буяу эшләрен башкаралар. Ремонт, проект документациясе белән билгеләнгән карарның сакланышын, гомуми тышкы торыш һәм төсләрне куллануны, исәпкә алып башкарылырга тиеш;
- якын-тирә территориядә үскән яшел үсентеләрнең, газоннарның, бордюр ташларының, кече архитектура формаларының (алар булганда) сакланышын күзәтеп торалар, билгеләнгән территорияне әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән таләпләр нигезендә карап торалар;
- стационар булмаган объектлар янында чүп савытлары урнаштыралар, чүп савытларын көн дәвамында кирәк булган саен, әмма бер тапкырдан да ким булмыйча, чистарталар, елга бер тапкырдан да ким булмыйча аларны буйыйлар;

17. Рөхсәт ителми:
- стаџионар булмаган объектлар янына янкормалар, козырьекалар, япма корылмалар һәм башка проект буенча каралмаган корылмалар төзү;
- стационар булмаган объектлар янында һәм аларның түбәләрендә тартмалар, товарлар, детальләр, башка төрле көнкүреш һәм җитештерү характерындагы предметларны җыю, шулай ук стационар булмаган объектларны склад максатында файдалану;
- стаџионар булмаган объектлар арасында янгынга каршы булдырылган ачыклыкларны җиһазлар, калдыклар белән каплау;
- стаџионар булмаган объектларны газоннарда, мәйданчыкларда (балалар өчен, ял итү, спорт белән шөгыльләнү , транспорт стоянкаларында), су үткәрү һәм канализация челтәрләренең сак зоналарында, торбаүткәргечләр, торак бина тәрәзәләренә, сәүдә предприятиеләренең витриналарына кадәр - 20 метрдан ким булмыйча, агач кәүсәсенә кадәр 3 метрдан ким булмыча урнаштыру.

## VII. Төзелеш эшләре барган урыннарга гомуми таләпләр.

1. Төзелеш мәйданчыкларын карап тоту, ремонт, төзелеш һәм башка төрле эшләр тәмамланганнан соң төзекләндерү төзүче җилкәсенә төшә.

Төзелеп бетмәгән, төзелеш эшләре алып барылмый торган төзелеш объектлары төзелеш челтәрләре белән ябылган булырга тиеш.

2. Төзелеш, ремонт һәм башка шундый төр эшләр башланыр алдыннан һәм эшләр башкарылган чорда түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:
- хокук актлары таләпләренә туры китереп, төзелеш мәйданчыгы территориясенең бөтен периметры буенча типлаштырылган коймалар урнаштырырга;
- төзелеш мәйданчыгы коймасының гомуми тотрыклылыгын, эксплуатацион куркынычсызлыгын тәэмин итәргә;
- төзелеш мәйданчыгын коймаларның техник торышын күзәтеп торырга, пычрактан, кардан, боздан һәм чит язулардан үз вакытында чистартып торырга;
- төзелеш мәйданчыгы территориясенә кергән урында, гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә җавап бирә торган, төзелеш объектының мәгълүмат щитын урнаштырырга һәм аны тиешле хәлдә тотарга;
- җәяүлеләр өчен вакытлыча тротуарлар урнаштыруны тәэмин итәргә;

- төзелеш мәйданы периметры буенча тышкы яктыртуны тәэмин итәргә;
- төзелеш мәйданчыгыннан каты көнкүреш, зур габаритлы һәм төзелеш калдыкларын, билгеләнгән тәртиптә, чыгаруны оештыруны тәэмин итәргә; төзелеш чүп-чарының, төзелеш материалларының якын-тирә территориягә эләгүен булдырмаска;
- эшләр башкарылган вакытта, гамәлдәге җир асты инженер коммуникацияләрен, тышкы яктырту челтәрләрен, яшел үсентеләрне һәм кече архитектура формаларын саклауны тәэмин итәргә;
- эшләр тәмамланганнан соң, эш барышында җимерелгән һәм зыян салынган юл катламнарын, яшел үсентеләрне, газоннарны, тротуарларны, сөзәк урыннарны, кече архитектура формаларын яңадан торгызырга.

3. Төзелеш материаллары, җиһазлары, автотранспорт һәм күчмә механизмнар, ярдәмче биналар, эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең вакытлыча урнашу өчен көнкүреш вагоннары, төзелеш калдыкларының транспорт партияләрен вакытлыча саклау һәм җыю өчен билгеләнгән урыннар, төзелеш оешмасы проекты нигезендә, төзелеш мәйданнары чикләрендә урнаштырыла.

## VIII. Авыл җирлеге территориясен бәйрәмчә (вакыйгаларга карата) бизәүгә гомуми таләпләр

1.Авыл җирлеге территориясен бәйрәмчә (вакыйгаларга карата) бизәү дәүләти һәм җирле бәйрәмнәр вакытында, истәлекле, мәдәни, спорт чаралары белән бәйле башка тантаналы чаралар үткәрү көннәре (алга таба - бәйрәм көннәре һәм чаралар үткәрү көннәре) вакытында башкарыла.

Чарага бәйле рәвештә бәйрәмчә (вакыйгаларга карата) бизәлеш афишалар, паннолар урнаштыру, декоратив элементлар һәм композицияләр куюны, шулай ук бәйрәмчә (вакыйгаларга карата) яктырткычлар (яктылык гирляндалары һәм элементлары, сеткалар, күләмле яктылык композицияләре, яктылык проекцияләре һәм башкалар) куюны үз эченә ала. Бәйрәмчә (вакыйгаларга карата) бизәлеше конструкцияләре аерым торучы һәм (яки) бинаның фасадындагы конструкцияләр рәвешендә урнаштырылырга мөмкин.

Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары предприятие һәм оешма җитәкчеләре белән берлектә бәйрәмгә карата предприятие, оешмаларның витриналарын, аларның фасадларын бизәү урыннарын һәм күләмнәрен билгелиләр.

Торак пунктларның бәйрәм һәм тематик бизәлешен монтажлау һәм демонтажлау күләмнәре һәм сроклары муниципаль хокукый актлар белән раслана.

Мәдәни мирас объектларында, шулай ук аларның территорияләрендә һәм мәдәни мирас объектларын саклау зоналарында бәйрәмчә һәм тематик бизәлешләрне монтажлау, үз компетенциясе кысаларында һәм гамәлдәге законнар нигезендә, мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы Комитеты белән килештерелергә тиеш.

Бәйрәмчә (вакыйгаларга карата) бизәлеш элементларын ясаганда һәм урнаштырганда юл хәрәкәтен җайга салучы техник чараларыны урыныннан алырга, зыян салырга һәм аларны күз күременә комачауларлак итеп куярга ярамый.

Бәйрәмчә (вакыйгаларга карата) бизәү элементларын кую, кулланылыш вакытында әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркынычсызлык таләпләренә җавап бирерлек булуын тәэмин итәләр.

2 Объектларның бәйрәм һәм тематик бизәлеше бәйрәм көненә кадәр 5 көн кала, ә Яңа елга – 20 нче декабрьгә кадәр билгеләнә.

3. Россия Федерациясенең Дәүләт флагын, Татарстан Республикасы флагын, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре флагларын бәйрәмчә бизәлештә һәм башка чараларда куллану «Россия Федерациясе Дәүләт флагы турында» 2000 нче елның 25 нче декабрендәге 1-ФЗ номерлы Федераль конституцияче Законда, «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 нчы елның 14 нчы июлендәге 2284 нче номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хокукый актлар белән каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. 22 нче июньдә үткәрелә торган Хәтер һәм кайгы көнендә Россия Федерациясе Президентының, 1996 нчы елның 8 нче июнендәге 857 нче номер белән кабул ителгән, «Хәтер һәм кайгы көне турында» Указы нигезендә, Россия Федерациясе дәүләт флаглары төшерелә.

5. Массакүләм чаралар алдан расланган программалар нигезендә, расланган вакытта һәм билгеләнгән урыннарда гына үткәрелә. Мондый чаралар үткәргәндә аларны оештыручылар чаралар үткәрү урынын һәм барлыкка килгән зыянны, бозылуларны төзекләндерүне тәэмин итәләр.

## IX. Җирлек территориясен җыештыру һәм карап тотуга гомуми таләпләр

1. Авыл җирлеге территориясен җыештыру һәм карап тоту түбәндәгечә башкарыла:

1) җәйге чорда - 15 апрельдән 14 октябрьгә кадәр;

2) кышкы чорда-15 октябрьдән 14 апрельгә кадәр.

Әлеге срокларга, һава шартларына бәйле рәвештә, җирлек башкарма комитеты тарафыннан төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

Җирлек территориясен карап тоту һәм җыештыру махсус оешмаларны җәлеп итү юлы белән җирле бюджет акчалары хисабына башкарыла.

2. Авыл җирлеге территориясен чистарту җирлек территориясен карап тоту, җыештыру буенча системалы эшләр башкару юлы белән, шулай ук җирлек Башкарма комитетының хокукый актлары нигезендә каралган массакүләм чаралар (өмәләр) үткәрү юлы белән башкарыла.

3. Җәйге чорда авыл җирлеге территориясен җыештыру (коры һава шартларында су сибү), урам-юл челтәре объектларының һәм ясалма өслекле башка территорияләрнең тузан һәм пычракларын юу, барлык территориядән чүп-

чар җыю, гомуми файдалануда булган территорияләрдә үләнне даими рәвештә чабу (үлән биеклеге 15 см дан артык булса), ел саен, 1 июньгә кадәр, кече архитектура формаларын, бакча һәм урам җиһазларын, чүп савытларын, спорт һәм балалар мәйданчыкларын, коймаларны, бордюрларны буяу, яфраклар коелган чорыда, тәүлегенә бер тапкыр, яфракларны җыю һәм чыгару аша башкарыла.

Җыелган һәм сибереп алынган чүп-чар, чабылган үлән, ботаклар билгеләнгән таләпләргә туры китереп чыгарылырга тиеш.

Агачлардан яфраклар коелу чорында җыелган яфракларны, җылы яратучы үсемлекләрне җылыту очракларыннан тыш, агач һәм куаклар астына җыю тыела.

4. Гомуми кулланыштагы территорияне җыештыру кышкы чорда үз эченә юл катламнарын һәм тротуарларны кардан, боз катламнарын һәм чүп - чардан чистартуны; җәяүлеләр йөри торган урыннарга ком сибүне, юл өсләрен бозлавыкка каршы материал белән эшкәртүне, язгы чорда карны йомшартып эрегән кар суларын агызу эшләрен оештыруны ала.

Җирлек территориясендә башкарыла торган чистарту эшләренең технологиясе һәм режимнары, һава шартларына бәйсез рәвештә, транспорт чаралары һәм җәяүлеләрнең тоткарлыксыз хәрәкәтенә комачаулык итәргә тиеш түгел.

Автомобильләр йөри торган юллардан һәм аның янәшәсендәге тротуарлардан чистартылган кар киң урамнарда һәм мәйданнарда аерым полосага, юл аслары булган очракта юл асларына, калган урамнарда юл кырыйларына (юл йөрү өлешенең киңлегенә карап, урамның бер яки ике ягына да) җыела һәм көртләргә салына. Кар көртенең киңлеге 2 метрдан артмаска тиеш;

Җәяүлеләр йөри торган юллардан чистартып алынган чиста, йомшак карны, ишегалларыннан җыела торган карны да кертеп, яшел үсентеләрнең сакланышы һәм эрегән кар сулары агып китешен тәэмин итү шарты белән, яшелләндерелгән территорияләрдә җыярга рөхсәт ителә.

Тротуарларда, җәмәгать транспортын көтә торган тукталышларда, ишегалларында һәм башка җәяүлеләр йөри торган урыннарда һәм яшел үсентеләр утыртылгын территорияләрдә бозлавыкка каршы реагент сыйфатында техник тоз һәм сыек хлорлы кальций кулланырга рөхсәт ителми, шулай ук билгеләнгән тәртиптә килешенмәгән урыннарга кар чыгарырга һәм скларга рөхсәт ителми;

5. Җирлек территориясендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- урамнарны, мәйданнарны, яшел үсентеләр булган участокларны, газоннарны, пляжларны һәм гомуми файдалануда булган башка территорияләрне чүпләргә;

- грунт, чүп-чарны, коела торган төзелеш материалларын, җиңел тартмаларны, киселгән агачларны, брезент яки юлларны пычратуга юл куймаслык итеп башка материал белән капламыйча бер урыннан икенче урынга күчерү, шулай ук юлга, тротуарлага, юл кырыйларына яки юл янындагы газон полосасына түгелү мөмкинлеген булдырмаучы чаралар күрмичә төзелеш катнашмаларын һәм эретмәләрне (шул исәптән цемент-ком эремәсен, известь, бетон катнашмаларын) транспортларга;

- җирләү урыннарыннан читтә булган гомуми файдалану территорияләрендә мемориаль кабер ташлары урнаштыру;

- шул максатлар өчен каралмаган урыннарда транспорт чараларын юу, чистарту, һәм аларга техник хезмәт күрсәтү;

- биналарны һәм корылмаларны, һәйкәлләрне, мемориаль такталарны, агачларны, куакларны, кече архитектура формаларын һәм башка төзекләндерү элементларын җимерергә, аларга зыян китерергә, шулай ук аларны үз белдегең белән үзгәртеп ясау, үзгәртеп кору һәм башка урынга күчерү;

- мәгълүмати-басма продукцияне, җәмәгать транспортын көтү тукталышларында, йорт диварларында, баганаларда, рәшәткәләрдә (койма) һәм башка бу максатлар өчен каралмаган объектларда, язу, ясау, ябыштыру һәм элү;

- җирлек территориясендә, шул исәптән урман җирләре, су фонды җирләре, авыл хуҗалыгы өчен билгеләнгән җирләр территориясендә, шул максатлар өчен махсу билгеләнгән урыннардан башка, көнкүреш, төзелеш чүп-чарын, җитештерү калдыкларын, тартмаларны, агач калдыкларын, яфраклар, кар, сыек көнкүреш калдыкларын ташлау рөхсәт ителми;

- йөк транспортын һәм тагылмаларны, шулай ук башка махсус техниканы (тракторлар, үзйөрешле машиналар)милекче ихатасыннан яки транспорт чараларын урнаштыру өчен махсус билгеләнгән оешма предприятиеләрнец территориясеннән читтә булган урыннарда, бистә эчендәге юл читләрендә, пляжларда, ял итү урыннарында, саклау зоналарында, яшелләндерелгән территорияләрдә калдыру

- куркыныч йөкләрне (бензин, газ) ташу өчен билгеләнгән махсус техника һәм куркыныч тудыручы башка техникага керү һәм туктау(йөк тияү һәм бушату, билгеләнгән урыннарына баручы транзит юлларыннан тыш,, ).

6. Рөхсәтсез урыннарда калдыклар ташлаган затлар үз акчалары хисабына әлеге территорияне чистарталар һәм җыештыралар, ә кирәк булганда - җир кишәрлеген рекультивациялиләр.

20 тәүлек эчендә мондый зат табылмаган булса, калдыкларны җыю һәм территорияләрне рекультивацияләү әлеге территорияне җыештыру өчен җаваплы оешмалар тарафыннан башкарыла.

7. Билгеләнгән тәртиптә әлеге эшләр өчен бирелмәгән һәм муниципаль милектә булган җир кишәрлекләрендә (территорияләрдә) барлыкка килгән чүплекләрне бетерү эше вәкаләтле орган тарафыннан тәэмин ителә.

8. Машиналар йөри торган юллар бөтен киңлегенә төрле төрдәге пычрактан арындырылган һәм тулысынча чистартылган булырга тиеш. Җайга салу линияләре белән билгеләнгән күчеш, резерв полосалар ком һәм вак чүп-чарлардан даими рәвештә чистартылырга тиеш. Машиналар йөри торган юл өлешен юу вакытында су агымы белән тротуарларга, газоннарга, җәмәгать транспортын котү тукталышларына, бина фасадларына, сәүдә объектларына һәм башка объектларга якын урнашкан урыннарга чүпләрне юып төшерү рөхсәт ителми.

9. Юл буенда урнашкан чүп савытлары көненә бер тапкырдан да ким булмыйча, тукталыш мәйданчыкларында көнгә ике тапкыр чистартыла.

10. Ваклап сату базарлары (алга таба - базар) һәм аның янәшәсендәге территориядә төп җыештыру эшләре базар ябылганнан соң башкарыла. Көндез каты көнкүреш калдыклары белән тулган чүп савытларын чистарту эшләре башкарыла. Елның җәйге чорында базар территориясендә мәҗбүри рәвештә атнага бер тапкыр дымлы җыештыру башкарыла.

Базар территориясендә һәм аның янында урнашкан оешмаларга, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләренә, киоскларга, сәүдә палаткаларына һәм павильоннарга, көнкүреш калдыкларын чыгару һәм урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү тозмичә генә, эшчәнлек алып барырга рөхсәт ителми.

Башка сәүдә мәйданчыкларын, стационар булмаган ваклап сату челтәре, социаль-мәдәни билгеләнештәге объектлар территорияләрен җыештыру, елның җылы вакытында, алар ябылганнан соң, мәҗбүри алдан су сибеп башкарыла. Җыештыру эшләре көн дәвамында да башкарыла. Көндәлек көнкүреш калдыкларын даими чыгару тәэмин ителә.

Билгеләнмәгән урыннарда сәүдә итү тыела.

Урам сәүдәсе, шул исәптән сезонлы сәүдә, җирле үзидарә органнары белән килешү шарты белән махсус билгеләнгән урыннарда гына рөхсәт ителә.

Сезонлы сәүдә тәмамланганнан соң урамнарда, мәйданнарда һәм башка урыннарда күчмә арбалар, әрҗәләр, башка сәүдә җиһазлары һәм сәүдәдән соң чистартылмаган территорияне калдыру тыела.

11. Ял итү һәм кешеләр күпләп җыела торган барлык территорияләр дә, пляжлардан тыш, каты катламлы өслек яки үлән һәм яшел үсентеләр үскән җир булырга тиеш;

Кешеләр күпләп йөри һәм ял итә торган урыннарда җиһазландырылган һәм эшли торган бәдрәф кабиналары урнаштырылырга һәм алар бәдрәфләрне урнаштыру һәм карап тоту таләпләрнә җавап бирергә тиеш.

Ял итү һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннарның территорияләрендә яшелләндерү участокларын чәчәк түтәлләре, газоннар, аерым, төркемләп, рәтләп утыртылган үсентеләр һәм яшелләндерүнең башка мобиль формалары рәвешендә проектларга кирәк;

Каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм урнаштыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү төзмичә пляж ачу рөхсәт ителми.

Ял итү урыннары территорияләрендә яки кешеләр күпләп җыела торган урыннарда урнашкан фонтаннар, буалар, елга ярлары, пычранган саен, чистартылырга тиеш.

12. Халык күпләп ял итә торган урыннарның территорияләрендә рөхсәт ителми:

- территорияне җитештерү һәм куллану калдыклары белән пычратырга;

- автотранспорт чараларын юарга һәм ремонтларга, файдаланылган ягулык-майлау сыеклыкларын агызырга;

- газоннарга, табигый һәм ясалма яшелләндерү объектларына зыян китерергә;

- кече архитектура формаларына зыян китерергә һәм аларны билгеләнгән урыннарыннан күчереп куярга;

- өстәлләрдә һәм эскәмия артларында утырырга;

- законсыз рәвештә автотранспорт чараларының түләүле парковкаларын оештырырга;

- стаңионар булмаган объектларны килешенүләрсез урнаштырырга;

- тротуарларның асфальт-бетон өслеген, якын-тирәдәге яшел зоналарның һәм территорияләрне төзекләндерүнең башка элементларының бөтенлеген бозарга;

- каты көнкүреш калдыкларын, идарәче оешмалар белән калдыкларны урнаштыру турында килешү төземичә, халыктан каты көнкүреш калдыклары җыю өчен билгеләнгән контейнерларга салырга;

- тимер-бетон блоклар, баганалар, коймалар, шлагбаумнар һәм башка җайланмалар урнаштыру юлы белән тротуарларны рөхсәтсез капларга;

- учак кабызырга, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрергә, мангаллар һәм ачык ут ярдәмендә ризык әзерлү өчен башка җайланмалар кулланырга.

13. Йорт яны территориясен карап тоту үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- даими җыештыру;

- кое капкачларын, коеларны, су юлларын, ябык су агу торбаларын ремонтлау һәм чистарту.

- инженерлык челтәрләренең күзәтү коеларына, янгын вакытында су белән тәэмин итү чыганакларына (гидрантларга, сулыкларга һәм башкаларга) тоткарлыксыз якын килү мөмкинлеген тәэмин итү;

- каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны җыю һәм чыгару;

- яшелләндерү һәм утыртылган яшел үсентеләрне карап тору;

- кече архитектура формаларын карап тору, чираттагы һәм капиталь ремонт ясау.

Күп фатирлы йортның йорт яны территориясен (алга таба - йорт яны территориясе) түбәндәге тәртиптә җыештырылырга тиеш: тротуарларны, җәяүлеләр юлларын (бозлавык һәм тайгак булган очракта - ком сибү), ә аннары ишегалды территорияләрен җыештыру.

Идарәче оешмалар түбәндәгеләрен тәэмин итәләр:

- йорт яны территорияләрен атна саен һәм көн дәвамында чистарту – чисталык саклау;

- каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар урнаштыру;

- расланган график нигезендә каты көнкүреш һәм зур габаритлы калдыкларны чыгару;

- контейнерларны (бункерларны) һәм контейнер мәйданчыкларын, аларга керү урыннарын чисталыкта һәм төзек хәлдә тоту;

- подъездларга керү юлларында эскәмияләр, чүп савытлары кую;

- территорияне сезонлы эксплуатацияләүгә әзерләү, шул исәптән канауларны чистартып тоту, кар суларын люкларга агуны тәэмин итү;

- тайгак урыннарны комлы катнашмалар белән эшкәртү;

- яшел үсентеләрне һәм газоннарны саклау, квалификацияле карау;

- тышкы яктырту чараларының төзеклеген һәм караңгы төшү белән аларның кабызылуын тәэмин итү

- яшел үсентеләрнең сакланышын һәм бөтенлеген тәэмин итү;

- җәй көне һәм һава шартларында коры булганда газоннарга, чәчәк түтәлләренә, агачларга һәм куакларга су сибү;

- яңа агачлар һәм куаклар утырту.

14. Йорт яны территориясендә рөхсәт ителми:

- яфракларны, калдыкларның теләсә нинди төрләрен һәм чүп-чарны яндыру;

- хуҗалык мәйданыннан читтә керләр, кием-салым, келәмнәр һәм башка предметларны элү;

- контейнер мәйданчыкларына керү юлларын каплау;

- урам һәм юлларның машиналар йөри торган өлешенә, тротуарларга, газоннарга һәм яшел зоналарга контейнерлар (бункерлар) кую;

- йорт яны территорияләренең коймаларын үз белдеге белән урнаштыру;

- йорт ишегалларын үзеңчә үзгәртеп төзү;

- йорт яны территориясен көнкүреш һәм төзелеш калдыклары, төзелеш материаллары, шлак, башка җитештерү калдыклары белән чүпләү;

- юындык суларны, калдыкларны һәм чүпне түгү;

- транспрт чаралары өчен түләүле стоянкалар ясау;

- автомашиналары юу, ягулык һәм май түгү;

- кешеләр сәламәтлегенә һәм әйләнә тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган эшләр эшләү;

- сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләрен урнаштыру;

- учак кабызу, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрү, мангаллар һәм ачык ут ярдәмендә ризык әзерлү өчен башка җайланмалар куллану;

- яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар, спорт һәм хуҗалык мәйданчыкларында, елның фасылына карамастан, әлеге территорияләрдә эшләрне башкару аеруча кирәкле булган очраклардан тыш, торгызу эшләрен мәҗбүри үткәрү шарты белән транспорт чараларын, шул исәптән сүтелгәннәрен (ватыкларын) кую.

15. Йорт яны территориясен яшелләндергәндә йорт диварларыннан алып ябалдашы 5 метрлы агачларга кадәр аралык 5 метрдан да ким булмаска тиешлеген онытмаска кирәк. Зуррак агачлар өчен әлеге аралык 5 метрдан күбрәк, куаклар өчен 1,5 метр булырга тиеш. Куакларның биеклеге беренче каттагы тәрәзәләрнең аскы өлешеннән артмаска тиеш

16. Йорт подъездлары каршындагы мәйданчыклар, машиналар һәм җәяүлеләр йөри торган юллар каты өслекле булырга тиеш Каты өслек урнаштырылганда кар һәм яңгыр сулары агу мөмкинлеге каралырга тиеш.

17. Торак йортларда урнаштырылган җәмәгать билгеләнешендәге биналарда йортның торак өлешеннән изоляцияләнгән керү юллары булырга тиеш, шул ук вакытта персонал транспортын калдыру урыны ишегалды территориясеннән читтә урнашырга тиеш.

## X. Җирлек территориясен яшелләндерүгә гомуми таләпләр.

1. Яшел үсентеләр территорияне төзекләндерүнең мәҗбүри элементы булып тора. Җирлек территориясендә яшелләндерүнең ике төре кулланылырга мөмкин: стационар - үсемлекләрне грунтка утырту һәм мобиль - үсемлекләрне махсус күчмә савытларга (контейнерлар, вазоннар һәм башкаларга) утырту.

2. Яшелләндерү объектларында башкарылган эшләргә таләпләр:

- яшелләндерү объектлары янында төзелеш мәйданчыкларын оештырганда, киртәләр кую, түбән ботакларны һәм киң ябалашларны кисү, агач кәүсәләрен бәйләү юлы белән беррәттән саклагыч чаралар да күрергә кирәк;
- территорияне вертикаль планлаштыру, җир асты коммуникацияләре салу, юлларны һәм тротуарларны тозекләндерү яшелләндерү эшләре башланыр алдыннан төгәлләнергә тиеш;
- туфрак катламын бозуга бәйле ремонт, төзелеш һәм башка эшләр башкарганда туфракның уңдырышлы катламын салдырырга һәм сакларга кирәк, ә эшләр тәмамланганнан соң бозылган җир участокларын һәм яшеллекне торгызырга кирәк;
- яфракларны һәм үләннәрне киләчәктә компостлау яки билгеләнгән тәртиптә түгү шарты белән өемнәргә җыярга кирәк;
- транспорт чаралары узуга комачаулаучы объектны саклау элементларын, бортның биеклеге 0,5 метрдан артмаган декоратив коймалар яки 0,5 метрдан артмаган биеклектәге баганалар, урнаштыру.

3. Яшел үсентеләрнең хуҗалары:

- яшел үсентеләрне саклауны һәм квалификацияле карауны тәэмин итәләр;
- җәй коне һәм һава шартлары коры булганда газоннарга, чәчәк түтәлләренә, агачларга һәм куакларга су сибәләр;
- яңа агачлар һәм куаклар утырталар һәм күчереп утырталар;
- яшелләндерү объектларында сулыклар булган очракта аларны чисталыкта тоталар һәм 10 елга бер тапкырдан да ким булмаган капиталь чистарту эшләре үткәрәләр.

4. Яшелләндерелгән территорияләрдә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

- яшелләндерү эшчәнлеген тәэмин итү һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән төзелешләрдән тыш башка төзелешләр урнаштыру;
- үз белдегең белән агач һәм куак утырту яки кисү, газоннарны һәм чәчәк түтәлләрен юк итү;
- ял итү һәм уеннар уйнау өчен паркларның мемориаль зоналары газоннарында, гомуми файдаланудагы яшелләндерү объектлары булган бульварларда тукталу;
- кышкы уеннар өчен махсус билгеләнгән урыннардан читтә урнашкан яшелләндерү объектларында чаңгыда һәм чаналарда шуу;
- бу урыннарны бакча буларак казу;
- газоннарда һәм чәчәк түтәлләрендә йорт хайваннарын йөретү;
- яфракларны, үләнне, ботакларны яндыру, шулай ук аларны су агу юлларына һәм башка сууткәргеч җайланмаларга салу;
- себереп алынган чүпне газоннрга чәчеп салу;

- учак кабызу, шул исәптән ачык уттан файдалануны күздә тоткан чаралар үткәрү, мангаллар һәм ачык ут ярдәмендә ризык әзерлү өчен башка җайланмалар куллану;

- агачларны кисеп аларга механик җәрәхәтләр ясау;

- агачларның тамырларын кәүсәсеннән 1,5 метрдан якын ераклыкта ачу һәм агачларның тамыр муентикларын җир яки төзелеш калдыклары белән күмү;

## XI. Сулыкларны тотуга гомуми таләпләр

1. Сулыкларны тоту территория хуҗалары һәм су балансын тотучылар тарафыннан башкарыла.

2. Сулыкларда түбәндәгеләр тыела:

- чүпләү, пычрату яки су юлларында буалар ясау;
- юынтык сулар, сәнәгать калдыклары һәм башка калдыклар белән пычрату.

3. Сулык территорияләрендә түбәндәгеләр тыела:

- автотранспорт юу;
- мал көтүе көтү;
- керләр юу.

4. Пляж территорияләре билгеләнгән санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килергә тиеш.

Коену сезоны башланганчы пляжлар санитар эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендәге вәкаләтле дәүләт органы һәм Татарстан Республикасының аз сыешлы суднолар буенча дәүләт инспекциясе (сулыкны суднолар йөртү максатлары өчен куллану очрагында) тарафыннан карап тикшерелергә һәм файдалануга тапшырылырга тиеш.

Пляж территорияләре коткару чаралары, бәдрәфләр, медицина пунктлары, чүп-чар җыю урналары, пляж җиһазлары (күләгәләүче корылмалар, киенеп чишенү урыннары, ятаклар һәм башкалар) белән җиһазландырылырга тиеш.

5. Төзекләндерү эшләренә җәлеп ителгәнтехникадан һәм авария-коткару хезмәтләренеңтехникасыннан тыш, пляж территориясенә транспорт чараларына керү тыела.

## XII. Йорт хайваннарын, терлекләрне, кош-кортларны тоту тәртибе турында.

1. Йорт һәм авыл хуҗалыгы хайваннарын тоту, федераль һәм республика законнары таләпләре нигезендә, аларның хуҗалары тарафыннан гамәлгә ашырылырга тиеш.
2. Авыл җирлегендә яшәүчеләргә авыл хуҗалыгы терлекләрен (сыер, сарык, кәҗә, дуңгызлар һәм башкаларны) һәм кошларны йорт яны участоклары булган шәхси торак йортлар территорияләрендә тоту рөхсәт ителә.
3. Йорт хайваннарын авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән билгеләнгән урыннарда көтү рөхсәт ителә.

Торак пунктларың урамнарында терлекләрен йөреткән мал хуҗалары хайваннарның яшел үсентеләргә, чит милеккә китергән зыяннарын гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә каплыйлар.
Терлекләрен авыл хуҗалыгы предприятиеләренең авыл хуҗалыгы җирләрендәге йөреткән өчен,аларның хуҗалары чәчүлекләргә килгән зыянны гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә каплыйлар.
4. Җәмәгать урыннарында көтүчеләрдән башка йөргән күзәтүчесез хайваннар тотылыргаһәм ябып куелырга тиеш.
Хайваннарны аулаганда (тотканда) гуманлык нормаларын үтәргә кирәк.

## XII. Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чараларына гомуми таләпләр

1. Тышкы мәгълүмат чаралары, учреждениеләрнең атамалары һәм эш вакытлары күрсәтелгәннәреннән тыш, вәкаләтле орган белән килешенгән паспорт нигезендә урнаштырыла һәм эксплуатацияләнә.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чараларының хуҗалары аларның тиешле халәттә булуын тәэмин итәләр, Тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннарын үз вакытында ремонтлыйлар һәм җыештыралар.

Тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чараларын реклама яки мәгълүмати хәбәр урнаштырмыйча торгызу һәм эксплуатацияләү, мәгълүмат кырына зыян китерү, шулай ук тышкы реклама яки мәгълүматны полиэтилен пленка һәм башка материаллар белән каплау, ябыштырып кую рөхсәт ителми.

Реклама яки мәгълүмати конструкциянең хуҗасы территорияне төзекләндерү эшен һәм (яки) фасадның тышкы кыяфәтен монтажлауны (демонтажны) өч тәүлек эчендә башкара.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат урнаштыру чаралары, аларның фундамен блогы булган очракта, фундамент блогы белән бергә сүтеп алынырга тиеш.

Тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштырганда корылмаларга һәм объектларның бизәлешенә зыян китерү, шулай ук аларның бөтенлеген, ныклыгын һәм тотрыклылыгын киметү рөхсәт ителми

Тышкы мәгълүмат чаралары типлаштырылган һәм индивидуаль итеп ясалган булырга мөмкин, ләкин алар Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы закон таләпләренә туры килергә тиеш.

2. Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру рөхсәт ителми:

- аерым торучы конструкцияләр рәвешендә индивидуаль яки күпфатирлы торак йортлар территориясендә;
- бинадагы тәрәзә уемнарын, витриналарның пыяласын, тәрәзәләрне томаларлак итеп;
- адреслы атрибутиканы (урам исемнәрен һәм йорт номерларын күрсәтүче билгеләрне) капларлак итеп ;
- мәгълүмат кырының гомуми мәйданыннан 10% тан артык булган урында, коймаларда яки биналардагы элмә такталар рәвешендәге модульле

конструкцияләр, шулай ук щит һәм витрина рәвешендәге конструкцияләрдән тыш, «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Федераль законның 9 матдәсе нигезендә мәҗбүри булмаган мәгълүматны (оешманың фирма исемен (исемен), аның урнашу урыны (адресы) һәм эш режимы турында мәгълүматны), аерым алганда, товарлар һәм хезмәтләр исемлеге, биналарны арендалау, сату турында мәгълүматны урнаштыру;
- тексттан башка гына сурәтләрне үз эченә алган мәгълүмат урнаштыру;
- фасадның төсе, архитектур фоны белән ярашмаучы;
- бер үк төрле мәгълүмати конструкцияләрне кулланып, кабатланучы мәгълүматларны, түбәндәгеләрне исәпкә алмыйча:
- Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы закон таләпләрен үтәү нигезендә башкарылган мәгълүмат;
- берничә урам киселешендә яки ике урамнар арасында урнашкан территориядә урнашкан бина фасадларының һәрберсендә урнаштырылган мәгълүмат;
- автозаправка станцияләре фасадларында урнаштырылган мәгълүмат;
- җемелдәвек утлар кулланып эшләнгән;
- телефон номерлары, сайтлар, электрон почта адреслары күрсәтелгән.

## XIV. Коммуникацияләрне төзегәндә, ремонтлаганда, реконструкцияләгәндә җир эшләрен үткәрүгә төп таләпләр

1. Җирлек территориясен төзекләндерү белән бәйле җир, төзелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм үткәрү, җир эшләрен башкаруга ордерны рәсмиләштерү һәм алу, җирлек Башкарма комитетының хокукый актларында билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.
2. Элек утыртылган яшел үсентеләрне казып алырга яки күчереп утыртырга кирәк булса, билгеләнгән тәртиптә җирлек башкарма комитеты карарын рәсмиләштерергә һәм яшел үсентеләрне казып алырга яки күчереп утыртырга кирәк.
3. Җирлек буенча хәрәкәтне вакытлыча чикләү яки туктату, юлның ике ягыннан да заказчылар һәм эшләрне башкаручылар, төгәлләү сроклары, эшләр башкарылган урыннарны әйләнеп узарга мөмкин булган маршрутлар күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган, мәгълүмати щитларне мәҗбүри урнаштыру шарты белән, җирлек Башкарма комитетының вәкаләтле органы тарафыннан бирелгән рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән щитның формасы һәм эчтәлеге рохсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең тиешле административ регламенты белән билгеләнә.
4. Гамәлдән чыккан ордерлар нигезендә төзелешләрдә, ремонт эшләрендә, коммуникацияләрне төзегәндә үткәрелгән җир эшләре рөхсәтсез дип таныла.

## XV. Бина һәм корылма (алардагы бүлмәләр) милекчеләренең якын тирә территорияне төзекләндерүдә катнашу тәртибе

1. Җирлек территорияләренең тиешле санитар торышын тәэмин итү,

әйләнә-тирә мохитне пычратудан саклау һәм яклау чараларын тормышка ашыру максатыннан, аларны җыештыру һәм санитар халәтен тиешле дәрәҗәдә тоту өчен хуҗалык итүче субъектларга һәм физик затларга әйләнә-тирә территорияләр беркетелә.

2. Территорияләрне (җир кишәрлекләрен) җыештыру, чистарту һәм санитар карап тоту буенча эшләрне башкару, законда яки килешүдә башка затлар булмаса, оештыру-хокукый формалары нинди булуына бәйсез рәвештә, физик һәм юридик затларга йөкләнә:

- идарәче оешмалар - күп фатирлы йортларның йорт яны территориясен, шулай ук төп фасадка кадәр 5 метр радиуста яки урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр күп фатирлы йорт территориясе каршындагы җир участогын (объект юл буенда урнашкан очракта);
- социаль өлкә учреждениеләре (мәктәпләр, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, мәдәният, сәламәтлек саклау, физкультура һәм спорт учреждениеләре) – бирелгән җир кишәрлеге чикләрендәге территорияләрне, шулай ук төп фасад каршындагы җир участогыннан 10 метр радиуста урнашкан территорияне яисә урамның машиналар йөрү өлешенә кадәр урынны (объект юл буенда урнашкан очракта), ә башка яклардан - 10 метр радиуста;
- идарәче оешма белән килешү булмаган очракта, күпфатирлы торак йортлардагы кеше яшәми торган бүлмәләрне эксплуатацияләүче затлар, эксплуатациягә алынган бүлмәләрнең бөтен озынлыгында, киңлеге - 10 м итеп яисә юл бордюрына кадәр урынным (объект юл буенда урнашкан очракта) тирә-юньне җыештыралар;
- сәнәгать предприятиеләре һәм төрле милек формасындагы оешмалар – үз объектларына керү юлларын, тротуарларны, алар янындагы коймаларны, санитар-сак зоналарын җыештыралар. Предприятиеләрнең санитар-сак зоналары гамәлдәге санитар кагыйдәләр һәм нормаларның таләпләренә туры китереп билгеләнә;
- төзүче оешма – төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә, төзелеш мәйданчыкларының якын-тирә территорияләрен 50 м радиуста һәм аларга керү юлларын 50 м радиуста;
- торак йортларның хуҗалары – бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә (яки җир кишәрлеге билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, гамәлдәге чиге буенча) һәм йорт каршындагы территорияне 5 м ераклыкта яки урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);
- стационар булмаган объектлар (лотоклар, киосклар, павильоннар һәм башка стационар булмаган сәүдә объектлары) һәм сезонлы кафе хуҗалары – җир кишәрлеге объектын урнаштыру өчен бирелгән территория һәм тышкы чикләрдән 10 м ераклыкта һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр (объект юл буенда урнашкан очракта);
- базарларның идарәче компанияләре, сәүдә һәм җәмгать туклануы оешмалары (рестораннар, кафе, кибетләр) – бирелгән җир кишәрлеге чикләрендәге территорияләрне һәм кишәрлектән читтә 50 м радиустагы якын

тирә территорияне һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр урынны (объект юл буенда урнашкан очракта);

- биналарның, корылмаларның милекчеләре яки башка хокук ияләре – бина, корылма яки бирелгән җир кишәрлеге чикләре буйлап һәм кишәрлек чикләреннән 10 м радиуста урнашкан якын-тирә территория һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр урынны (объект юл буенда урнашкан очракта);
- автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса чикләрендә һәм башка җир кишәрлекләрендә урнашкан ягулык салу станцияләре – бирелгән җир кишәрлеге чикләрендәге территория һәм участок чикләреннән 50 м радиуста булган якын-тирә территорияне һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр урынны;
- гражданнарның бакчачылык, яшелчәчелек һәм коммерцияле булмаган дача берләшмәләре – бирелгән җир кишәрлеге территориясен һәм участок чикләреннән 10 м радиуста булган якын-тирә территорияне һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр урынны (объект юл буенда урнашкан очракта);
- җирләү урыннары – бирелгән җир кишәрлеге чикләрендә һәм участок чикләреннән 10 м радиуста булган якын-тирә территорияне;
- гомуми файдаланудагы территорияләр – бурычлар вәкаләтле органнарга йөкләнә;
- җир кишәрлекләренә хокуклары булуган затлар – бирелгән җир кишәрлеге чикләрендәге территорияләрне (яки җир кишәрлеге билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелмәгән очракта, гамәлдәге чиге буенча) һәм җир кишәрлегенең тышкы чикләреннән 5 м ераклыкта урнашкан территорияне һәм урамның машиналар йөри торган өлешенә кадәр урынны (объект юл буенда урнашкан очракта);

## XV. Кагыйдәләрнең үтәлешен контрольдә тоту

1. Физик, юридик һәм вазыйфаи затлар авыл җирлеге территориясен төзекләндерү буенча әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне тәэмин итәләр.
2. Әлеге кагыйдәләрне бозган өчен административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә (федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралган нормаларны һәм кагыйдәләрне үз эченә алган, аларны үтәмәгән өчен административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нигезендә җаваплылык билгеләнгән нигезләмәләрдән тыш) җаваплылыкка тартыла.
3. Төзекләндерү өлкәсендәге закон таләпләрен һәм муниципаль хокукый актларны үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыкка тарту әлеге таләпләрне үтәүдән һәм җибәрелгән җитешсезлекләрне төзәтүдән азат итми.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зирекле аввыл җирлеге**
**Башлыгы**
**Совет Рәисе** **В.А.Данилова**